**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений
в Семейный кодекс Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 ноября 2018 года

**Статья 1**

Внести в Семейный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 12 (II часть); 2011, № 9 (I часть); 2012, № 6 (I часть); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I); 2018, № 22 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 8:
а) часть 1 изложить в следующей редакции:
«1. Заключение брака производится в личном присутствии лиц, вступающих в брак, по истечении месяца и не позднее двенадцати месяцев со дня подачи заявления в орган записи актов гражданского состояния в дату и во время, которые определены лицами, вступающими в брак, при подаче ими заявления о заключении брака.»;
б) часть 2 изложить в следующей редакции:
«2. При наличии уважительных причин орган записи актов гражданского состояния по месту государственной регистрации заключения брака может разрешить заключение брака до истечения месяца со дня подачи заявления о заключении брака.»;

2) в части 3 статьи 74 слова «физических лиц» исключить;

3) в статье 102:

а) наименование дополнить словами «и (или) задолженности по уплате неустойки за несвоевременную уплату алиментов»;

б) в части 1 слова «от уплаты задолженности по алиментам или уменьшение этой задолженности» заменить словами «от уплаты задолженности по алиментам и (или) задолженности по уплате неустойки за несвоевременную уплату алиментов или уменьшение задолженности по алиментам и (или) задолженности по уплате неустойки за несвоевременную уплату алиментов»;

в) часть 2 после слов «задолженности по алиментам» дополнить словами «и (или) задолженности по уплате неустойки за несвоевременную уплату алиментов».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования за исключением пункта 2 статьи 1 настоящего Закона.

2. Пункт 2 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу с 1 января 2019 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
30 ноября 2018 года
№ 91-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"1. Никахлашу өйләнешүче затларның шәхси катнашында, граждан хәле актларын теркәү органына гариза биргән көннән соң бер ай узгач һәм унике айдан да соңга калмыйча, өйләнешүче затлар никахлашу турында гариза биргәндә билгеләгән датада һәм вакытта башкарыла.";
б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"2. Нигезле сәбәпләр булган очракта никахлашуны дәүләт теркәвенә алу урыны буенча граждан хәле актларын теркәү органы никахлашу турында гариза бирелгән көннән алып бер ай узганчы ук никахлашуны рөхсәт итәргә мөмкин.";

2) 74 статьяның 3 өлешендә "физик затларның кертемнәрен" сүзләрен "кертемнәрне" сүзенә алмаштырырга;

3) 102 статьяда:
а) исемендә "бурычын" сүзеннән соң "һәм (яисә) алиментларны вакытында түләмәгән өчен неустойка бурычын" сүзләрен өстәргә;
б) 1 өлештә "алимент бурычын түләүдән азат итү яисә бу бурычны киметү" сүзләрен "алимент бурычын һәм (яисә) алиментларны вакытында түләмәгән өчен неустойка бурычын түләүдән азат итү йә алимент бурычын һәм (яисә)

алиментларны вакытында түләмәгән өчен неустойка бурычын киметү” сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә “бурычын” сүзеннән соң “һәм (яисә) алиментларны вакытында түләмәгән өчен неустойка бурычын” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 30 ноябрь
№ 91-ТРЗ